КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1247

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә өстәмә дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү турында» 2015 ел, 16 ноябрь, 857 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә өстәмә дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү турында» 2015 ел, 16 ноябрь, 857 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә» сүзләрен «2 510,0 сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибендә:

2 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йорт;»;

унберенче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы икенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин